# Әткәй киткәч

Рамил Чурагулов сүзләре

Фәнир Галимов көе




1
Әткәй киткәч, ятим булып калдык,
Моң югалды, сүнде инде жыр,
Әнкәй безне юатырга теләп,
Әйтер иде: "Бер көн ул кайтыр."

*Кушымта:*
Ике толымкаен бер толымга
Үреп куйды әнкәй, ни итсен.
Аны язмыш бер көн ирсез итте
Безне язмыш итте әтисез.

2
Әтисезгә яшәү җиңел түгел.
Һәркем суга, кага ятимне.
Әнкәбезнең азмы җанын кыйдык,
"Алып кайт" дип безнең әтине.

3
Дөнья йөген тартып барулары
Җиңел түгел толга, ирсезгә.
Алар паек җәннәт рәхәтләрен
Исән чакларында күрергә.